ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» гыйнвар 2022 ел № 02

**«2022 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 декабрендәге 378 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.«2022 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 декабрендәге 378 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары исемлеге, аларга карата 2020 елның 1 гыйнварына кадәр мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына күчерелгән баланы карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең күләменә күчеш чорына төзәтмәләр коэффициентлары кулланыла»;

1.2 1 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «2020 елның 1 гыйнварына кадәр мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына исәпләнгән балага ата-ана түләве күләменә (азык-төлек продуктларының бәясеннән тыш) күчеш чорына карата төзәтмә коэффициентлары.

1.3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2021 елның 12

декабрендәге 378 номерлы карарына кушымталарда «2021 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләрен «2020 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**